ЗАКОН
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

Об отдельных вопросах государственного регулирования торговой деятельности в Республике Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
19 октября 2026 года

Статья 1. **Предмет регулирования настоящего Закона**

Настоящий Закон в соответствии с Федеральным законом от 28 декабря 2009 года № 381-ФЗ «Об основах государственного регулирования торговой деятельности в Российской Федерации» (далее – Федеральный закон) регулирует отдельные вопросы, связанные с реализацией полномочий органов исполнительной власти Республики Татарстан в области государственного регулирования торговой деятельности на территории Республики Татарстан.

Статья 2. **Основные понятия, используемые в настоящем Законе**

Основные понятия, используемые в настоящем Законе, применяются в том же значении, что и в Федеральном законе.

Статья 3. **Полномочия органов исполнительной власти Республики Татарстан в области государственного регулирования торговой деятельности**

1. Кабинет Министров Республики Татарстан осуществляет следующие полномочия в области государственного регулирования торговой деятельности:

1) реализация государственной политики в области торговой деятельности на территории Республики Татарстан;

2) установление порядка размещения нестационарных торговых объектов, в том числе мобильных торговых объектов, на землях или земельных участках, находящихся в муниципальной собственности, а также на землях или земельных участках, государственная собственность на которые не разграничена;

3) установление порядка организации на территории Республики Татарстан ярмарок и продажи товаров (выполнения работ, оказания услуг) на них, за исключением случаев, когда организатором ярмарки является федеральный орган государственной власти;

4) установление требований к организации продажи товаров (в том числе товаров, подлежащих продаже на ярмарках соответствующих типов и включению в соответствующий перечень) и выполнения работ, оказания услуг на ярмарках с учетом требований федерального законодательства;

5) иные предусмотренные Федеральным законом полномочия в области государственного регулирования торговой деятельности.

2. Орган исполнительной власти Республики Татарстан, уполномоченный в области государственного регулирования торговой деятельности (далее – уполномоченный орган), осуществляет следующие полномочия:

1) установление порядка разработки и утверждения органами местного самоуправления схемы размещения нестационарных торговых объектов;

2) формирование, ведение торгового реестра Республики Татарстан в соответствии с законодательством Российской Федерации, представление обобщенных сведений, содержащихся в торговом реестре, в федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по выработке государственной политики и нормативно-правовому регулированию в сфере внутренней торговли, и уполномоченный федеральный орган исполнительной власти, осуществляющий функции по формированию официальной статистической информации о социальных, экономических, демографических, экологических и других общественных процессах в Российской Федерации;

3) разработка и реализация мероприятий, содействующих развитию торговой деятельности на территории Республики Татарстан;

4) разработка и утверждение нормативов минимальной обеспеченности населения площадью торговых объектов для Республики Татарстан, в том числе для входящих в ее состав муниципальных образований, в соответствии с методикой расчета указанных нормативов, утвержденной Правительством Российской Федерации;

5) размещение и обновление на своем официальном сайте в информационно-телекоммуникационной сети «Интернет» информации, предусмотренной частью 3 статьи 20 Федерального закона;

6) проведение информационно-аналитического наблюдения за состоянием рынка определенного товара и осуществлением торговой деятельности на территории Республики Татарстан;

7) иные предусмотренные Федеральным законом полномочия в области государственного регулирования торговой деятельности.

Статья 4. **Особенности размещения и использования нестационарных торговых объектов на земельных участках, находящихся в частной собственности**

1. Размещение нестационарных торговых объектов на земельных участках, находящихся в частной собственности, осуществляется в соответствии со схемой размещения нестационарных торговых объектов.

2. Порядок включения нестационарных торговых объектов, размещенных на земельных участках, находящихся в частной собственности, в схему размещения нестационарных торговых объектов и исключения таких объектов из этой схемы

устанавливается уполномоченным органом с учетом положений, предусмотренных частями 14 – 17 статьи 10 Федерального закона. Указанный порядок должен предусматривать требование к нестационарному торговому объекту и месту его размещения.

3. Порядок размещения и использования нестационарных торговых объектов на земельных участках, в зданиях, строениях, сооружениях, находящихся в частной собственности, устанавливается собственниками земельных участков, зданий, строений, сооружений с учетом требований, определенных законодательством Российской Федерации и законодательством Республики Татарстан.

4. Осуществление торговой деятельности в нестационарном торговом объекте, размещенном на земельном участке, находящемся в частной собственности, допускается при условии включения такого нестационарного торгового объекта в схему размещения нестационарных торговых объектов.

5. Включение нестационарного торгового объекта, размещенного на земельном участке, находящемся в частной собственности, в схему размещения нестационарных торговых объектов осуществляется органом местного самоуправления на основании заявления юридического лица, индивидуального предпринимателя или физического лица, не являющегося индивидуальным предпринимателем и применяющего специальный налоговый режим «Налог на профессиональный доход» в течение срока проведения эксперимента, установленного Федеральным законом от 27 ноября 2018 года № 422-ФЗ «О проведении эксперимента по установлению специального налогового режима «Налог на профессиональный доход», которые намереваются использовать нестационарные торговые объекты для осуществления торговой деятельности (далее – заявление). Заявление должно содержать сведения о месте размещения (местах размещения мобильных торговых объектов, если предполагается использовать более одного места размещения), внешнем виде, назначении, характеристиках и сроках размещения нестационарного торгового объекта.

6. Форма заявления, указанного в части 5 настоящей статьи, перечень прилагаемых к нему документов, в том числе документов, подтверждающих согласие собственника земельного участка и согласие иного лица, во владении и пользовании которого находится этот земельный участок (при наличии такого лица), на размещение нестационарного торгового объекта на этом земельном участке, порядок предоставления заявления и прилагаемых к нему документов, а также сроки рассмотрения заявления органом местного самоуправления устанавливаются уполномоченным органом с учетом требований статьи 10 Федерального закона.

Статья 5. **Программы развития торговли**

1. Для содействия развитию торговли Кабинет Министров Республики Татарстан и органы местного самоуправления могут принять решение о разработке соответственно программы развития торговли в Республике Татарстан и муниципальных программ развития торговли (далее в настоящей статье – программы развития торговли), учитывающих социально-экономические,

экологические, культурные и другие особенности развития Республики Татарстан, муниципальных образований.

2. Программа развития торговли в Республике Татарстан разрабатывается уполномоченным органом с учетом требований статьи 18 Федерального закона и настоящей статьи и утверждается Кабинетом Министров Республики Татарстан.

3. Муниципальная программа развития торговли разрабатывается и утверждается местной администрацией муниципального образования с учетом требований статьи 18 Федерального закона и настоящей статьи. Утверждение муниципальной программы развития торговли осуществляется с учетом мнения уполномоченного органа.

4. В программах развития торговли определяются:

1) цели, задачи и ожидаемые результаты развития торговли с учетом достижения установленных нормативов минимальной обеспеченности населения площадью торговых объектов;

2) мероприятия, направленные на достижение целей государственной политики в области торговой деятельности, в том числе мероприятия по оказанию приоритетной поддержки в развитии торговли товарами российским производителям товаров, субъектам малого или среднего предпринимательства, формированию конкурентной среды, развитию торговли в сельской местности;

3) объем и источники финансирования мероприятий, содействующих развитию торговой деятельности;

4) основные показатели эффективности реализации программ развития торговли;

5) порядок организации реализации программ развития торговли и порядок контроля за их реализацией.

5. Основными показателями эффективности реализации программ развития торговли являются:

1) достижение установленных нормативов минимальной обеспеченности населения площадью торговых объектов;

2) повышение доступности товаров для населения;

3) формирование торговой инфраструктуры с учетом видов и типов торговых объектов, форм и способов торговли, потребностей населения;

4) создание условий для увеличения спроса на товары российских производителей товаров.

Статья 6. **Вступление в силу настоящего Закона**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением статьи 4 настоящего Закона.

2. Статья 4 настоящего Закона вступает в силу с 1 марта 2027 года.

3. Юридические лица, индивидуальные предприниматели и физические лица, не являющиеся индивидуальными предпринимателями и применяющие специальный налоговый режим «Налог на профессиональный доход» в течение срока проведения эксперимента, установленного Федеральным законом от 27 ноября 2018 года № 422-ФЗ «О проведении эксперимента по установлению

специального налогового режима «Налог на профессиональный доход», которые осуществляют торговую деятельность в нестационарных торговых объектах, размещенных до 1 сентября 2026 года на земельных участках, находящихся в частной собственности, вправе осуществлять торговую деятельность в указанных нестационарных торговых объектах без их включения в схему размещения нестационарных торговых объектов до 1 сентября 2027 года.

Глава (Раис)
Республики Татарстан Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
29 октября 2026 года
№ 74-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗАКОНЫ

Татарстан Республикасында сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салуның аерым мәсьәләләре турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2026 елның 19 октябрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Россия Федерациясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу нигезләре турында» 2009 елның 28 декабрендәге 381-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарының вәкаләтләрен гамәлгә ашыруга бәйле аерым мәсьәләләрне җайга сала.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр**

Әлеге Законда кулланыла торган төп төшенчәләр Федераль законда билгеләнгән мәгънәләрендә кулланыла.

3 статья. **Сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә түбәндәге вәкаләтләрне башкара:

1) Татарстан Республикасы территориясендә сәүдә эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәтен гамәлгә ашыруны;

2) муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын, шул исәптән мобиль сәүдә объектларын, урнаштыру тәртибен билгеләүне;

3) Татарстан Республикасы территориясендә ярминкәләрне һәм аларда товарлар сатуны (эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне) оештыру тәртибен, ярминкәне оештыручы федераль дәүләт хакимияте органы булган очраклардан тыш, билгеләүне;

4) федераль законнар таләпләрен исәпкә алып, ярминкәләрдә товарлар (шул исәптән тиешле типлардагы ярминкәләрдә сатылырга һәм тиешле исемлеккә кертелергә тиешле) сатуны һәм эшләр башкаруны, хезмәтләр күрсәтүне оештыруга таләпләр билгеләүне;

5) сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Федераль законда каралган башка вәкаләтләрне.

2. Сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә вәкаләтле Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органы (алга таба – вәкаләтле орган) түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

1) җирле үзидарә органнары тарафыннан стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасын эшләү һәм раслау тәртибен билгеләүне;

2) Россия Федерациясе законнары нигезендә Татарстан Республикасы сәүдә реестрын төзүне, алып баруны, сәүдә реестрындагы гомумиләштерелгән белешмәләрне эчке сәүдә өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы федераль башкарма хакимият органына һәм Россия Федерациясендә социаль, икътисадый, демографик, экологик һәм иҗтимагый процесслар турында рәсми статистик мәгълүмат формалаштыру функцияләрен гамәлгә ашыручы вәкаләтле федераль башкарма хакимият органына җибәрүне;

3) Татарстан Республикасы территориясендә сәүдә эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итә торган чараларны эшләүне һәм гамәлгә ашыруны;

4) халыкны сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин итү нормативларын исәпләүнең Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган методикасы нигезендә Татарстан Республикасы өчен, шул исәптән аның составына керүче муниципаль берәмлекләр өчен, күрсәтелгән нормативларны эшләүне һәм раслауны;

5) Федераль законның 20 статьясындагы 3 өлешендә каралган мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге үзенең рәсми сайтында урнаштыруны һәм яңартуны;

6) Татарстан Республикасы территориясендә аерым бер товар базарының торышына һәм сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыруга мәгълүмати-аналитик күзәтү үткәрүне;

7) сәүдә эшчәнлеген дәүләт тарафыннан җайга салу өлкәсендә Федераль законда каралган башка вәкаләтләрне.

4 статья. **Хосусый милектәге җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру һәм алардан файдалану үзенчәлекләре**

1. Хосусый милектәге җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасы нигезендә гамәлгә ашырыла.

2. Хосусый милектәге җир кишәрлекләрендә урнашкан стационар булмаган сәүдә объектларын стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кертү һәм мондый объектларны әлеге схемадан төшереп калдыру тәртибе, Федераль законның 10 статьясындагы 14 – 17 өлешләрендә каралган нигезләмәләрне исәпкә алып, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә. Күрсәтелгән тәртип стационар булмаган сәүдә объектына һәм аның урнашу урынына карата таләпне күздә тотарга тиеш.

3. Хосусый милектәге җир кишәрлекләрендә, биналарда, төзелмәләрдә, корылмаларда стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру һәм алардан файдалану тәртибе, Россия Федерациясе законнарында һәм Татарстан Республикасы законнарында билгеләнгән таләпләрне исәпкә алып, җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар милекчеләре тарафыннан билгеләнә.

4. Хосусый милектәге җир кишәрлегендә урнашкан стационар булмаган сәүдә объектында сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру мондый стационар булмаган сәүдә объектын стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кертү шарты белән рөхсәт ителә.

5. Хосусый милектәге җир кишәрлегендә урнашкан стационар булмаган сәүдә объектын стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кертү, стационар булмаган сәүдә объектларыннан сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен файдаланырга ниятләгән юридик затның, индивидуаль эшкуарның яисә индивидуаль эшкуар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кертү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән эксперимент үткәрү срогы дәвамында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллана торган физик затның гаризасына (алга таба – гариза) нигезләнеп, җирле үзидарә органы тарафыннан гамәлгә ашырыла. Гаризада стационар булмаган сәүдә объектының урнашкан урыны (бердән күбрәк урнаштыру урыныннан файдалану каралган булса, мобиль сәүдә объектларының урнашкан урыннары), тышкы күренеше, билгеләнеше, характеристикалары һәм урнашу сроклары турында белешмәләр булырга тиеш.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән гариза формасы, аңа теркәлә торган документлар, шул исәптән әлеге җир кишәрлегендә стационар булмаган сәүдә объектын урнаштыруга җир кишәрлеге милекчесенең ризалыгын һәм бу җир кишәрлегенә ия булган һәм аннан файдалана торган бүтән затның (мондый зат булган очракта) ризалыгын раслый торган документлар, исемлеге, гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны тапшыру тәртибе, шулай ук җирле үзидарә органы тарафыннан гаризаны карау сроклары, Федераль законның 10 статьясы таләпләрен исәпкә алып, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

5 статья. **Сәүдәне үстерү программалары**

1. Сәүдә үсешенә ярдәм итү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм җирле үзидарә органнары Татарстан Республикасының, муниципаль берәмлекләрнең социаль-икътисадый, экологик, мәдәни һәм башка үзенчәлекләре исәпкә алынган тиешле Татарстан Республикасында сәүдәне үстерү программасын һәм сәүдәне үстерүнең муниципаль программаларын (әлеге статьяда алга таба – сәүдәне үстерү программалары) эшләү турында карар кабул итәргә мөмкин.

2. Татарстан Республикасында сәүдәне үстерү программасы, Федераль законның 18 статьясы һәм әлеге статья таләпләрен исәпкә алып, вәкаләтле орган тарафыннан эшләнә һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан раслана.

3. Сәүдәне үстерүнең муниципаль программасы, Федераль законның 18 статьясы һәм әлеге статья таләпләрен исәпкә алып, муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе тарафыннан эшләнә һәм раслана. Сәүдәне үстерүнең муниципаль программасын раслау вәкаләтле орган фикерен исәпкә алып гамәлгә ашырыла.

4. Сәүдәне үстерү программаларында түбәндәгеләр билгеләнә:

1) халыкны сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин итүнең билгеләнгән нормативларына ирешүне исәпкә алып, сәүдәне үстерүнең максатлары, бурычлары һәм көтелә торган нәтиҗәләре;

2) сәүдә эшчәнлеге өлкәсендә дәүләт сәясәте максатларына ирешүгә юнәлдерелгән чаралар, шул исәптән Россия товар җитештерүчеләренә, кече һәм урта эшкуарлык субъектларына товарлар белән сәүдә итүне үстерүдә өстенлекле ярдәм күрсәтү, конкурентлы мохит булдыру, авыл җирендә сәүдәне үстерү чаралары;

3) сәүдә эшчәнлеген үстерүгә ярдәм итү чараларын финанслау күләме һәм чыганаклары;

4) сәүдәне үстерү программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәле булуның төп күрсәткечләре;

5) сәүдәне үстерү программаларын гамәлгә ашыруны оештыру тәртибе һәм аларны гамәлгә ашыруны тикшереп тору тәртибе.

5. Сәүдәне үстерү программаларын гамәлгә ашыру нәтиҗәле булуның төп күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

1) халыкны сәүдә объектлары мәйданы белән минималь тәэмин итүнең билгеләнгән нормативларына ирешү;

2) халык өчен товарларның сатып алырлык булуын арттыру;

3) сәүдә объектларының төрләрен һәм типларын, сәүдә рәвешләрен һәм ысулларын, халык ихтыяҗларын исәпкә алып, сәүдә инфраструктурасын булдыру;

4) Россия товар җитештерүчеләре товарларына ихтыяҗны арттыру өчен шартлар тудыру.

6 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон, әлеге Законның 4 статьясыннан тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 4 статьясы 2027 елның 1 мартыннан үз көченә керә.

3. Хосусый милектәге җир кишәрлекләрендә 2026 елның 1 сентябренә кадәр урнаштырылган стационар булмаган сәүдә объектларында сәүдә эшчәнлеген гамәлгә ашыручы юридик затлар, индивидуаль эшкуарлар һәм индивидуаль эшкуар булмаган һәм «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын кертү буенча эксперимент үткәрү турында» 2018 елның 27 ноябрендәге 422-ФЗ номерлы Федераль законда билгеләнгән эксперимент үткәрү срогы дәвамында «Һөнәри керемгә салым» махсус салым режимын куллана торган физик затлар күрсәтелгән стационар булмаган сәүдә объектларында сәүдә эшчәнлеген, аларны стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру схемасына кертмичә, 2027 елның 1 сентябренә кадәр гамәлгә ашырырга хокуклы.

Татарстан Республикасы
Рәисе

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ ГЛАВЫ (РАИСА) РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН •
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2026 ел, 29 октябрь
№ 74-ТРЗ